СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
24 сентябрь 2018 ел

Карар
№ 1-38

Омар авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында» 2-16 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2018 елның 30 августындагы 02-01-18-2018 номерлы прокурор тәкъдиме, 2018 елның 03августындагы № 334-ФЗ Федераль закон, РФ Салым кодексының 391 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Омар авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында» 2-16 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- карарның 3 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидлыкның I һәм II төркеме булган инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалар, торак фонды, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән җирләргә, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен бирелгән җирләргә, шулай ук дача хуҗалыгына, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә гомерлек мирас итеп биләүгә бирелгән җирләргә карата».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә «Нократ» («Вятка») район газетасында, Мамадыш муниципаль районының (http://mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгы Н.П.Князевага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Н.П.Князева